| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 523 08 июнь 2015 ел

Нурлат муниципаль районында «Балалар Сабантуе» бәйрәменә әзерләнү һәм үткәрү турында

Тәрбиягә бала алучы гаилә институты үсешенә ярдәм итү максатларында һәм Нурлат муниципаль районында 2015елга чараларның район планы нигезендә КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районында 2015 елның 19 июнендә «Балалар Сабантуе» бәйрәмен уздырырга.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Нурлат муниципаль районында «Балалар Сабантуе» бәйрәменә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты составы (1 нче кушымта);
- Нурлат муниципаль районында «Балалар Сабантуе» бәйрәменә әзерлек һәм аны уздыру буенча чаралар планы (2 нче кушымта);
- Нурлат муниципаль районында «Балалар Сабантуе» бәйрәмен үткәрү программасы (3 нче кушымта);
- Нурлат муниципаль районында «Балалар Сабантуе» бәйрәмен уздыру чыгымнарының сметасы (4 нче кушымта).

3. «Нурлат муниципаль районының Финанс бюджет палатасы» муниципаль учреждениесенә 2015 елга район бюджетында каралган чаралар чикләрендә бәйрәм чараларын тиешле статьялар буенча финанслауны тәкъдим итәргә.

4. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә җәмәгать туклануы, ваклап сату системасында эшләүче предприятиеләр продукциясен сату эшен оештырырга һәм тәэмин итәргә.

5. Бәйрәм чаралары вакытында юлларда җәмәгать тәртибен саклауны һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүне Нурлат районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлегенә тәкъдим итәргә.

6. «Нурлат үзәк район хастаханәсе» ДАССУ массакүләм чараларда катнашучыларга медицина хезмәте күрсәтүне тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

7. «Татмедиа» ААҖ филиалларына «Дуслык» газетасы редакциясенә («Дуслык», «Туслах»), «Нурлат» телерадиокомпаниясенә Нурлат муниципаль районындагы «Балалар Сабантуе» бәйрәме барышын үз вакытында яктыртуны тәкъдим итәргә.

8. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны бәйрәм чаралары уздыру урынына транспортировкалауны тәэмин итәргә.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгына йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Ә.К. Габдуллин